| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МИЧУРИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МИЧУРИН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ КАРАР**

2023 елның 3 июле №25

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 17 ноябрендәге 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә яңа редакциядә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 17 ноябрендәге 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

**«4. Башкарма комитет вәкаләтләре**

Куелган бурычларны гамәлгә ашыру һәм үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Башкарма комитет түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга мөмкин.

1.Җирлекнең Башкарма комитеты:

1) планлаштыру, бюджет, финанс һәм исәпкә алу өлкәсендә:

җирлек бюджеты проектын, җирлекне комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары проектларын эшли;

-җирлек бюджетын үтәүне тәэмин итә, җирлекне комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнарын һәм программаларын үтәүне оештыра;

-җирлек бюджетының үтәлеше турында хисап, җирлекнең комплекслы социаль-икътисадый үсеше планнарының һәм программаларының үтәлеше турында хисаплар әзерли;

- җирлекнең икътисады һәм социаль өлкәсе торышын чагылдыра торган статистик күрсәткечләрне җыюны һәм күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнарына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тапшыруны оештыра;

2) җирлек территориясендә муниципаль милеккә идарә итү, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә: